МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 163/о

ПРИКАЗ　　　　　　　　БОЕРЫК

«07» 11 2023

2024 елга Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә бәя кую нигезләренең 88 пункты, Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 31 августындагы 262 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 2024 елга Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга бер компонентлы тарифлар билгеләү турында карар кабул итәргә.

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.М.Фроловка йөкләргә.

Министр　　　　　　　　М.М.Айзатуллин

Министерство строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан * Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы * Отдел контроля исполнения документов